КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 май г.Казань № 311

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1194 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 1.7 пункттагы «тиешле» сүзен «I – III» саннарына алмаштырып, түбәндәге үзгәрешне кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче; 2022 ел, 25 октябрь, 1137 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 1.7 пункттагы «тиешле» сүзен «I – III» саннарына алмаштырып, түбәндәге үзгәрешне кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 522 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 август, 855 нче; 2023 ел, 20 ноябрь, 1491 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле

әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

35 пунктның «в» пунктчасында «$36^1$» саннарын «$23^6$» саннарына алмаштырырга;

36 пунктта:

«а» пунктчасында «$36^1$» саннарын «$23^6$» саннарына алмаштырырга;

«в» пунктчасында «$36^1$» саннарын «$23^6$» саннарына алмаштырырга.

4. Бу карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин